**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,42319

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2019 елның 5 июленнән № 50-300

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2006 елның 23 ноябрендәге 10-76 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милкендә булган туктатылган яки (һәм) эш башкарылмаган төзелеш объектлары буенча төп фондларны һәм чыгымнарны гамәлдән чыгару тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (01.05.2019 ел редакциясендә), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында " 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, "Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2006 елның 23 ноябрендәге 10-76 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милкендә булган туктатылган яки (һәм) эш башкарылмаган төзелеш объектлары буенча төп фондларны һәм чыгымнарны гамәлдән чыгару тәртибе турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 5 пункты көчен югалткан дип санарга;
- 7 пунктта "(бәлки кире кагылырга да мөмкин)» сүзләрен төшереп калдырырга һәм (“кире кага”) сүзе белән тулыландырырга;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» https://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырырга (халыкка игълан итәргә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы В.М. Козлов